**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге составына керүче Куаклы авылында гражданнар жыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

22 ноябрь, 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 1ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар жыены нәтижәләре белән гражданнар жыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- электроматериаллар сатып алу, һәм урнаштыру

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар жыены нәтижәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия жыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар жыенында катнашучы 16 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар жыенында катнашучылар саны –15 кеше.

Тавыш биру нәтижәләре буенча жыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар жыенында катнашучы 15 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен жыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар жыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Куаклы авылында гражданнар жыенын узган, гражданнар жыены нәтижәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2022 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Куаклы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең)

сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- электроматериаллар сатып алу, һәм урнаштыру

мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Куаклы авылы гражданнар жыены нәтижәсен авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка житкерергә.

4. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Куаклы авылы гражданнар жыены нәтижәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл жирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматынын рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче
Мәләкәс авыл жирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев